# Мәктәп хәбәрчесе

**№1** **(№14)** **гыйнвар 2020 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


*/Мөхәррир сүзе /*

## *Алда юллар – кайсын сайларга...*

Әле кайчан гына уку елын башлаган идек, инде аның икенче уртасын ваклыйбыз. Имтиханнарны ничек бирермен дә, киләчәк тормышымны ничек дәвам итәрмен дип уйламаган бер генә чыгарылыш сыйныф укучысы бар микән? Алардан бигрәк, әти-әниләрнең күңелләре баласы өчен икеләтә борчыла.

Илебездә 40 меңләп һөнәр барлыгы билгеле. Шуларны барлап, чыгарылыш сыйныф укучыларының киләчәккә планнары да билгеләнгәндер. Ә кайберләре әле һаман: “Кем булырга? Җәмгыятьтә нинди һөнәр модада икән?” - дип баш вата торгандыр. “Мода” дигәннән...Бүген яшьләр, хәтта авыл җирлегендә туып-үсеп, авыл мәктәбен тәмамлаучылар да икътисадчы, хисапчы, менеджер, программист кебек һөнәрләрне үзләштерергә кызыгалар. БДИ имтиханнарын уңышлы гына тапшырып, табиб, нефтьче, мәдәният өлкәсендәге төрле һөнәрләр белән үз тормышын бәйләргә җыенучылар да бар. **Һөнәр ул - күңел кебек, җан кебек**. Теләгәненңне үзләштерү өчен ниндидер югары уку йортлары баскычларын үтеп керәсе бар. Бүгенге вәзгыятьтән чыгып караганда, яшьләребезнең күбесе Казан каласын сайлый. Бу шәһәр татарстанлыларны гына түгел, чит төбәкләрне, чит илләрне дә кызыктыра һәм сыйдыра. Шунлыктан уку йортларының баллары да, аттестатка таләпләре дә югарыдан. Танылган КФУ бусагасыннан атлау өчен кайбер баллар суммасын да әйтеп үтәсе килә. 2019 нчы ел өчен уртача баллар: Нефть һәм газ белгечлеге - 257, Лингвистика - 291, Халыкара мөнәсәбәтләр - 377, Прикладная информатика - 261, География - 225, Картография һәм геоинформатика - 234, Экономика факультетлары - 269 балл таләп итә. КНИТУ да иң минималь баллар: Химик технология - 213, Педагогик белем - 209, Нефть һәм газ эшкәртү -223, Туризм - 234, Информатика - 234 балл җыюны сорый. Бүгенге көндә урта махсус белгечлеккә керү дә аттестатта “яхшы” һәм “бик яхшы” билгеләрдән уртача балл саный. Әти-әни кесәсенә сугып, түләп укымас өчен уртача баллары югары булырлык итеп, тырышып укырга кирәк. Түләүләр дә хәзер 100 меңнән кимен табармын димә. Укучыларыбыз шуны да аңласын иде: керү генә дә мөһим түгел, уку да инә белән кое казу мәкален исбатлый. Авыррак үзләштерелә торган юнәлешләр булганда, төптәнрәк уйласыннар дип телисе кала.

Соңгы елларда, син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала, дигәндәй, авыл хуҗалыгы өлкәсе өчен кирәк булган һөнәрләрне сайлаучылар бик аз. Кайда гына булмасын - шәһәрдәме, авылдамы, чит илдәме - кеше бер генә көн дә ипи-сөтсез, итсез, җиләк-җимеш, яшелчәсез яши алмый. Аларны безгә авыл хуҗалыгы бирә түгелме соң? Яшьләрнең ни өчен авыл хуҗалыгында көч куясы килми? Кайсы гына заманада яшәсәк тә, әби-бабайлар әйткән сүзләр көн кадагына суга: төзүче, туендыручы һәм дәвалаучылар һәрвакыт кирәк. Бүгенге көндә җәмгыять агроном һәм зооинженерларга аеруча кытлык кичерә. Шулардан чыгып булса да, укыгач эш тә табарлык, җаныңа ятарлык һөнәр сайласак иде. Авыл җирендә дә, теләгең булса, күпкә җиңел һәм җайлырак яшәп була. Әти-әниләребез яшәү мәгънәсен туган җирендә тапкан икән, ник балаларыбыз кадерледән кадерле вакытыбызны тәгәрмәч өстендә уткәрә торган шәһәрне сайлый? Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы белгечлекләренә юнәлтелгән программалар да бихисап, торыр урыннар да, өстәмә эш хаклары да каралган. Төптән уйлап эш итү генә сорала.

Хәзер инде бары тик тырышырга, уку йортларына керү өчен ныклап әзерләнергә кирәк. Укучылар бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, уку йортларында белемнәрен дәвам итеп, җирлегебезгә әйләнеп кайтырлар, намус белән хезмәт куярлар дип ышанып калыйк.

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

*/Укучылар иҗаты /*



## *Такталым*

Газизләрдән газиздер син миңа
Туган авылым минем - Такталым
Синдә тудым, синдә буйга җиттем
Үттедер синдә балачагым.

Кочагына кочып алган кебек
Урап алган сине урманнар
Алардагы кошлар һәм хайваннар
Барысы да синең туганнар.

Җәелеп киткән басу-кырларында
Һәрберсендә үсә мул уңыш.
Элек-электән үк алар безгә
Китергәннәр һәрчак зур табыш.

Иртә таңда уятадыр безне,
Кошларыңның моңлы тавышы.
Су буйларында да тыныч кына
Шаулашадыр үлән-камышың.

Челтерәп ага салкын чишмәләрең
Үзләренчә көйгә салынып.
Хуш исле чәчәкле болыннарда,
Оча күбәләкләр шатланып.

Мәңге яшә авылым, әй Такталым,
Син бит минем гомер бишегем.
Сине саклау минем бурычымдыр,
Син дип тибә минем йөрәгем.

***Әлфинә Гыйльметдинова,***
***XI сыйныф укучысы***

## *Түбән Майна мәчетенә 25 ел*

***/Бәйрәмнәребез /***

1994 елның 1 октябрендә халык күңелендә мәңгегә кереп калган вакыйга була: 50 елдан артык мәчетсез торганнан соң, ниһаять, авылның яңа гыйбадәт йорты ачыла. Инде менә ачылганга 25 ел үтеп тә киткән. Узган көз айларында, 25 еллык бәйрәменә әзерләнү максатыннан, мәчеттә төрле төзекләндерү эшләре башкарылды. Авылның ир-атлары мәчетне яңартуда күп көч куйды. Шактый кеше бу эшләр өчен акчалата да ярдәм иттеләр.



5 гыйнвар көнне мәчетебезнең юбилеена багышлап зур бәйрәм уздырылды. Әлеге олы чарада районыбыз башлыгы Камил абый Гилманов, мөхтәсиб Равил хәзрәт, төрле авылларның имамнары, читтән кайткан кунаклар һәм авылдашлар катнашты. Бәйрәм чаралары мәктәптә башланып китте. Сәламнар әйтеп Коръән укылганнан соң, авыл мәхәлләсе тарихына багышланган фильм күрсәтелде. Шуннан соң котлаулар һәм тәбрикләүләр булды. Директор һәм имам Рафик абый мәчеткә зур ярдәм иткән кешеләргә нәсел шәҗәрәләре ясалган картиналар бүләк итте. Котлаулардан соң сүз укучыларга бирелде. Башта кече яшьтәге укучылар һәм бакча балалары чыгыш ясады. Аннары 8-9 сыйныф кызлары мөнәҗәт әйттеләр. Гомумән алганда, барыбыз да мәчет тантанасына үз өлешебезне кертергә тырыштык. Күп кенә укучылар мәчет бәйрәме хөрмәтенә төрле эшләнмәләр һәм рәсемнәр ясап килгән иде. Ул бүләкләрдән залда бик матур күргәзмә оештырылды.



Мәктәптәге бәйрәм татарның күркәм гадәте булган чәй табыны белән дәвам итте. Шуннан соң кунаклар тәкбирләр әйтеп иске мәчет урынындагы һәйкәл янына киттеләр. Анда Рафик абый халыкны бу урынның тарихы белән таныштырды. Бәйрәм чаралары мәчеттә өйлә намазы белән тәгалләнде.

Авылда шундый рухлы, эчтәлекле бәйрәм-очрашулар күбрәк булган саен аның кадере, матурлыгы арта. Туган җиребез тирә-якка күркәм гадәте белән үрнәк булыр. Авылдашлар тагын да бер-берсенә якынаер дип ышанасы килә.

***Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина, Әминә Туктамышева, VIII сыйныф укучылары***

***/Мәктәп тормышы/***



## *Студентлар белән очрашу*

Мәктәбебездә күп еллардан бирле үткәрелеп килә торган студентлар белән очрашу быел да булып узды. Кунакка килгән кичәге укучыларыбыз берсе табиб, икенчесе укытучы, кайсы хисапчы һәм тагын төрле-төрле һөнәр ияләре булачак. Очрашуга килгән биш студентыбызның дүртесе Казан шәһәрендә белем ала. I курс студенты Сафиуллин Илсур КХТИ студенты. Ул технология укытучысы белгечлеген үзләштерә. Мәгыйзов Илфир КДАХА икътисад бүлегендә укый. Мөхәммәтҗанов Айрат – Ульян шәһәренең медицина институты студенты. КФУ студентлары Насыйрова Динә психология факультетының II курсында, Гафиятуллина Фәйрүзә, картография һәм геоинформатика бүлегенең III курсында белем алалар. Кунаклар уку йортларына керү тәртибен, мәктәптә алган белемнәрнең укуга нигез булып торуын, укуга җаваплырак карарга кирәклеген өлкән сыйныф укучыларына үтемле итеп аңлаттылар.

Чыгышлардан соң укучылар һәм укытучылар студентларга үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр. Тулаем алганда, очрашу киләчәктә һөнәр сайлаучылар өчен кызыклы үтте. Студентлар да һөнәрләрен үзләштергәч, җәмгыятькә дә, үзләренә дә файда китерелек хезмәт куярлар дигән теләктә калабыз.

***Алия Гыйззәтуллина, IXсыйныф укучысы***



**/Безгә кунак килде /**

## *Җылы очрашу*

Мәктәбебезгә "Татарстан" журналы вәкилләре килә дигәч, бераз дулкынланып та калган идек. Каләм ияләренең максаты нидән гыйбарәт тә, бездән ни таләп ителәикән дип торганда, алар килеп тә җиттеләр. Без алар белән тиз арада уртак тел табып, җылы аралашу да оештырып алдык.

**- Руфия апа, безнең авылга килүегезнең максаты нидән гыйбарәт?**

- Без соңгы елларда республикабызның татар авылларын барлап йөрибез. Гади халыкка якынаю максатыннан авыл, гаилә, мәктәпләр белән, аларның яшәү шарты белән танышып, үзенчәлекле якларын барлар өчен, төркемебез белән менә шулай йөрибез.

**- Сез үзегезнең һөнәр белән дә таныштырсагыз иде.**

- Мин бу журналистлык өлкәсендә инде күптәннән каләм чарлыйм. 2006 елдан бирле төрле басмаларда эшләп киләм. Һәр басманың үз теле бар. Хәзерге вакытта эшләгән басма белән "Ялкын" журналы телен чагыштыру авыр. Анда балаларга якын тел булса, монысы өлкәннәр өчен языла торган тел. Кечкенәдән шул өлкә белән кызыксынып тордым. Туганым Шәүкәт ага Галиев янында һәрчак язучылар җыела иде. Мин алар янында аралашып үстем, бигрәк тә Роберт абый Миңнуллин мине канатландырып тора иде. Балачак хыялының койрыгыннан тотып, журналист була алдым.

**- Руфия апа, менә без дә үзебезнең мәктәп гәзитен чыгарып киләбез. Ягъни журналистлык һөнәрендә беренче адымнарны атлыйбыз. Әйтегез әле, бу һөнәрне үзләштерү өчен эшне кайдан башларга кирәк?**

- Язарга, язарга һәм тагын язарга. Һәрвакыт үз өстеңдә эшләргә кирәк. Теләсә кайсы һөнәрне үз итәсең, хыялыңа барып җитәсең килсә – шул өлкәдә юнәлешне шомартырга кирәк.

**- Сезнең басмада төрле шәхесләрнең китап киштәләре күрсәтелә. Бу китаплар нинди юнәлешка карап сайлана?**

- Бу безнең бик кызыклы сәхифә. Монда китапларның иң кызыклылыры, яңалык алып килгәннәре, төрле телдә язылганнары сайлана. Ник әле, мәсәлән, татар милләте чит ил әдәбиятын укымаска тиеш. Луиза Янсуар тарафыннан булдырылган бу хезмәт бик кызыклы. Ул барлык китапларны укып бара. Шуңа бу басмалар белән сезгә дә танышырга тәкъдим итәм. Телне чарлау, сөйләмне үстерү, әдәби аралашу булдырыр өчен менә дигән ысул.

**- Сезнең белән килгән иптәшләрегезнең дә һөнәре бик кызыксындыра безне. Фотографлар турында иде сүзебез. (Безгә Александр Ефремов җавап бирә).**

- Әйе, безнең дә эшебез шулай ук бик мавыктыргыч. Басмалар өчен бик җаваплы хезмәт башкарабыз. Төшерә белер өчен, әле камераны каядыр төбәр өчен элек күрә белергә кирәк. Бу һөнәргә шулай ук укырга мөмкин. Бик кыска араларда үзегезгә икмәк табарлык шөгыль булдырып була. Төп эшегездән тыш та фотоаппарат белән берәр урында эшләп, гаиләгезгә өстәмә керем кертә аласыз.

**- Безгә Сезнең җылы әңгәмәгез бик ошады. Тулы, мавыктыргыч җавапларыгыз өчен рәхмәт. Безгә мондый әңгәмәләр, очрашулар бик кирәк тә, файдалы да.**

- Без үзебез дә Сезнең белән очрашуга бик шат. Хыялларыгыз тормышка ашсын, укуыгызда уңышлар теләп калабыз.

***Әңгәмәне Сара Насыйрова, Зөлфирә Сафиуллина, Әминә Туктамышева алып барды***

**/Котлыйбыз!/**




Гыйнвар аенда туучыларны туган көннәре белән котлыйбыз!


Бакча төркемендә тәрбияче ярдәмчесе булып эшләүче Рәмзия апа Сәгъдиева Яңа ел белән бергә 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Рәмзия апага гаиләсендә иминлек, тигезлек, сәламәтлек белән озын гомер теләп калабыз.

Физика һәм информатика укытучысы Фәнис абый Хөснуллинны, тәрбияче Альмира апа Бәшированы да гыйнварда булып узган гомер бәйрәмнәре белән котлыйбыз!

Яңа елның беренче көнендә Замалетдинова Инзиләгә 13 яшь, Хәбибрахманова Мәрьям гә 12 яшь, Камалов Илдуска 14 яшь, 18 гыйнварда Закирова Ләйсәнгә 8 яшь, 20 гыйнварда балалар бакчасына йөрүче Мансурга 4 яшь тулды! Кадерле дуслар. Барыгызны да туган көннәрегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез!

*/Укучылар иҗаты /*

## *Кыш аклыгы белән гүзәл*



Урамда ниндидер сызгыру тавышына игътибар иттем. Әйтерсең лә мине кемдер тышка чакыра. Тәрәзәдән күз салдым. Буран башланган икән: карны тегендә-монда уйнатып барлык җирне ап-ак карга күмеп йөри. Чисталыкны яраткангамы, әллә шаяртып кынамы – бөтен юлларны, булган эзләребезне йомшак кар белән каплый да, сөенеп карап тора үзе. Әллә бу буран малаемы икән? Бик тузына да, үз эшенә сокланып тора да тагын да үҗәтләнеберәк тотына. Малае гына дисән, барлык нечкәлекләрен белә үзе. Тышка чыгуга керфекләрне ябыштыра, җылы башлыкның төсен өнәмәгәнгә ахры, аны да акка күмә. Әби бәйләгән бияләемне дә ак мамык ясый. Буран уйлаганча, әйтерсең лә барлык нәрсә ак төстән генә торырга тиеш ..! Алай гына булса ярар иде, артыбыздан шуышып килеп, аркаларга сылана. Алдыңа чыгып бөтерелә дә, бит алмаларын чеметә. Юлларыңңны күмәргә күп сорамый, көрт ерып барырга калдыра. Йорт түбәләренә дә кары белән киң кырлы эшләпә кигерергә өлгергән. Кар катламы өй кыекларына сырланып түгәрәкләнгән дә, суыктан сакларга теләгәндәй, катып калганнар.

И, могҗазалы буран. Син бит Кыш малае. Малай гына булсаң да эшеңне яратып, бөтен кагыйдәләреңне үтисең шул. Синнән үрнәк кенә аласы да, бөтен эшебезне җиренә җиткереп эшләргә өйрәнәсе. Табигать бездән шуны көтмиме икән?

***Сара Насыйрова, IX сыйныф укучысы***

*/Безнең спорт/*



## *Шахмат ярышлары*

Шахматчылар өчен кышкы каникуллар кызу көрәш чоры булды. Безнең мәктәп укучылары Гафиятуллин Фаил, Хәйруллин Айназ, абыйлы-энеле Муса һәм Халит Нурматовлар 3нче гыйнвар көнне 18 яшькәчә булган шахматчылар арасында Аксубай районы беренчелегенә ачык чемпионатта көч сынаштылар. Барлык яшь дәрәҗәләре дә гомуми бәяләнгәнлектән, әлеге ярыш кызулыгы ягыннан алдагыларыннан бер дә калышмады. Нәтиҗәдә, Гафиятуллин Фаил 1 урынны яулауга иреште.

Гафиятуллин Фаилнең шахмат көрәше әле бу ярыш белән генә чикләнмәде. Ул Чаллы шәһәрендә узкән, тиз уйнала торган шахмат турнирында катнашып, 2нче урын яулап кайтты. Фаилне җиңүләре белән чын күңелдән котлыйбыз, аңа һәм калган шахматчыларыбызга киләчәктә зур уңышлар телибез!

## *Көрәш*

Мәктәбебезнең көрәшче егетләре дә сынатмый. 25-26 гыйнвар көннәрендә Зәй шәһәрендә Ринат Шәех улы Фәрдиев истәлегенә багышланган Рәсәйкүләм “Көрәш” ярышында үз авырлыкларында Камалов Илдус – II, Хәбибрахманов Ильяс – III урыннарны алып кайттылар. Егетләребезне чираттагы уңышлары белән котлыйбыз. Һәрвакыт шулай гаиләгезнең һәм туган авылыгызның горурлыгы булып яшәгез!




## *Табышмак әйтәм, тыңла*

*/Күңелле тәнәфес/*

Әрманстанда зур бер күл бар. Аның исеме биш хәрефтән тора. Шушы хәрефләрне файдаланып, биш географик атама төзеп карагыз. Алар түбәндәгеләр:

1. Рәсәйнең төньяк-көнбатышындагы елга.
2. Франциядәге иң зур елгаларның берсе.
3. Висла елгасының уңъяк кушылдыгы.
4. Кече Азиядәге зур күл исеме.
5. Европа дәүләтләренең берсендә башкала исеме.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:**
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова